| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2024 Балык Бистәсе штп. № 206пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында

Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында каралмаган көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслау мәсьәләләрендә вазыйфаи зат өчен хокук нормаларын куллануның киң чикләрен яисә нигезсезлеген билгели торган коррупциоген факторларны бетерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы нигезләмәне;

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия составын.

2. Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан чыгымнарны финанслауны әлеге карар белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә тиешле финанс елына «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карарында күрсәтелгән сумма чикләрендә тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3.Үз көчен югалткан дип танырга:

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турында» 16.01.2014 №06пи карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 15.07.2014 ел, №128пи карары.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы

буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 01.08.2024
№ 206пи карары белән
расланган

Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә тиешле елга Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында каралмаган көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслау өчен төзелә.

2. Әлеге Нигезләмә Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан (алга таба-резерв фонды) акчалар бүлеп бирү һәм алардан файдалану тәртибен билгели.

3. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясындагы 3 өлеше нигезендә резерв фонды күләме тиешле елга «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә һәм әлеге карар белән расланган чыгымнарның гомуми күләменең 3 процентыннан артмаска тиеш. Резерв фонды бюджетның чыгым өлешендә кирәк булган саен тотылырга мөмкин булган иң чик сумма буларак күрсәтелә. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында»карарына тиешле үзгәрешләр кертелгәндә, резерв фонды күләме ел дәвамында үзгәрергә мөмкин.

4.Резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнарны финанслау өчен юнәлтелә, шул исәптән:

4.1. стихияле бәла-казаларны һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү белән бәйле авария-торгызу эшләре һәм башка чаралар уздыру;

4.2. табигый бәла-казаларны һәм башка гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чараларын үткәрү;

4.3. иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә, үзешчән сәнгать иҗат коллективларына ярдәм итү;

4.4. кичектергесез ремонт һәм торгызу эшләре;

4.5. социаль – мәдәни өлкәне, физик культураны һәм спортны, мәгарифне һәм фәнне үстерүгә ярдәм итү;

4.6. җирле әһәмияттәге проблемалар буенча очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар үткәрү;

4.7. Балык Бистәсе муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен гражданнарга бер тапкыр бирелә торган премия түләү;

4.8. ашыгыч кирәк булган очракта дарулар, медицина билгеләнешендәге әйберләр, медицина җиһазлары сатып алу;

4.9. гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү, (шул исәптән янгыннар һәм техноген характердагы башка вәзгыятьләрне дәвалауга, алардан килгән зыянны бетерүгә), халыкка социаль ярдәм чаралары күрсәтү;

4.10. әйләнә-тирә мохитне саклау, гражданнар оборонасы, җирле әһәмияттәге табигатьне саклау, эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

4.11. район муниципаль берәмлекләренә финанс ярдәме күрсәтү (шул исәптән свода катнашканда һәлак булган гражданнарны җирләүне оештыруга бәйле чыгымнар);

4.12. Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына матди, бер тапкыр бирелә торган финанс һәм башка ярдәм күрсәтү.

5. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслауга резерв фондыннан акчалар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы, физик яисә юридик зат мөрәҗәгате нигезендә бүлеп бирелә.

Акча бүлеп бирү турындагы мәсьәләне карау, белдерелгән акчалар бюджетның башка чыгымнары буенча экономия хисабына табыла алмау шарты белән башкарыла.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары, юридик затлар резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгать белән бергә Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә (алга таба-Башкарма комитет җитәкчесе) күрсәтелгән максатларга чыгымнарның кирәклеген, кичектергесезлеген һәм көтелмәгәнлеген раслаучы документлар (шул исәптән китерелгән зыян турында органнар белешмәләре йә смета – финанс исәп – хисапларын һәм проект-смета документациясен дә кертеп, таләп ителә торган акча күләмен нигезли торган документлар) тапшыралар.

Мөрәҗәгать итүчеләр-физик затлар түбәндәге документларны тапшыралар:

1) гариза;

2) шәхесне таныклаучы документлар:

а) паспорт;

б) вакытлыча шәхес таныклыгы;

в) туу турында таныклык – 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган гаилә әгъзалары өчен;

3) индивидуаль шәхси счетның иминият номеры;

4) гаилә хәленә бәйле рәвештә никахлашу турында таныклык (яисә никахны өзү турында таныклык) ;

5) пенсия таныклыгы;

6) инвалидлык турында белешмә (ВТЭК);

7) ЕГРНнан өземтә, гаилә составы һәм матди-көнкүреш хәле турында белешмә;

8) гаиләнең һәр әгъзасы (ялгыз яшәүче граждан) тарафыннан акчалата алынган мөрәҗәгать итү аена кадәрге өч ай өчен керемнәр (хезмәт эшчәнлегеннән керемнәр булмау факты эштән китүе турында язулы хезмәт кенәгәсе белән раслана)турында белешмәләр;

9) гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның башка керемнәре турында белешмә, аларга:

а) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэмин ителеше, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән даими характердагы өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү;

б) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан азат ителгәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие;

в) эш бирүчеләр тарафыннан үз хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык яисә яшь буенча пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә эштән киткән элеккеге хезмәткәрләренә күрсәтелә торган матди ярдәм;

10) Авыр тормыш вәзгыятен раслый торган, кыйммәтле дарулар яисә медицина әйберләре сатып алу, операция үткәрү һәм операциядән соңгы чорда реабилитацияләү кирәклеген раслый торган документлар - сәламәтлек саклау учреждениеләреннән, оешмаларыннан;

11) Мөрәҗәгать итүчегә һәм (яисә) аның гаиләсенә янгын, су басу яисә башка табигый бәла – каза аркасында җитди зыян китерелүен раслый торган документлар-Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан, төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан яисә алар карамагындагы учреждениеләрдән, оешмалардан;

12) Банктагы счет реквизитларын күрсәтеп, банк кертеме шартнамәсе (яисә саклык кенәгәсе).

Тиешле документлар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатларга карап тапшырыла. Керемнәр турында белешмәләр керем чыганакларының булуына (булмавына) карап тапшырыла. Документларның һәм белешмәләрнең күчермәләре бер нөсхәдә тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче тапшырылган белешмәләрнең, шулай ук алар булган документларның дөреслеге өчен җаваплы. Тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр бирү матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

6.Башкарма комитет җитәкчесе 5 (биш) эш көне эчендә резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм чыгымнарның кирәклеген, кичектергесезлеген һәм көтелмәгәнлеген раслаучы документларны мәсьәләләрне хәл итү өчен резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясенә (алга таба – комиссия) җибәрә:

- резерв фондыннан акча бүлеп бирү кирәклеге яисә кирәк булмау турында;

- бүлеп бирелә торган акчаларның күләмен билгеләү турында.

7.Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

8. Комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра. Комиссия рәисе вазыйфаларын башкару мөмкин булмаганда яисә ул булмаганда рәис вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

9. Комиссия утырышы составының кимендә өчтән икесе булганда хокуклы.

10. Комиссия утырышлары Башкарма комитет җитәкчесеннән мөрәҗәгатьләр һәм документлар кергән саен уздырыла.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була. Утырыш беркетмәсенә комиссия рәисе имза сала.

Утырышта булмаган очракта комиссия әгъзасы карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырышта игълан ителә һәм беркетмәгә кушып бирелә.

Кабул ителгән карар белән килешмәгәндә комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә һичшиксез беркетелергә тиеш.

11. Комиссия секретаре әзерлекне гамәлгә ашыра һәм, комиссия рәисе белән килештереп, чираттагы утырышның датасын һәм вакытын билгели. Комиссия секретаре утырыш беркетмәсен алып баруны тәэмин итә. Секретарь вакытлыча булмаганда, аның функцияләре комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

12. Комиссия 10 (ун) эш көне эчендә карар чыгара. Комиссия карары рекомендация характерында. Комиссиянең кабул ителгән карары 3 (өч) эш көне эчендә Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрелә.

13. Резерв фондыннан акчалар Башкарма комитет күрсәтмәсе нигезендә бүлеп бирелә.

14.Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында Башкарма комитет күрсәтмәсе Балык Бистәсе муниципаль районының башкарма-боеру органнары һәм оешмалары карамагындагы (аларның оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан) әлеге чараларны гамәлгә ашыручы акчалар җитәрлек булмаган очракларда кабул ителә. Башкарма комитетның резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсендә ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны алучылар һәм үткәрелә торган чаралар буенча бүлү күрсәтелә. Акчаларны Башкарма комитет күрсәтмәләрендә каралмаган максатларга файдалану рөхсәт ителми.

15. Бүлеп бирелә торган акчаларның күләмен һәм аларны тоту юнәлешен күрсәтеп, резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында Башкарма комитет күрсәтмәләре проектларын комиссия секретаре Башкарма комитет җитәкчесенең тиешле йөкләмәсен алганнан соң 3 (өч) эш көне эчендә әзерли.

16. Эшчәнлек төрләре буенча резерв фондыннан акчалар бүлеп бирелә торган Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Балык Бистәсе муниципаль районы оешмаларының структур бүлекчәләре (аларның оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан) Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә сорала торган акчаларның күләмен, смета-финанс исәп-хисапларын да кертеп, нигезләп, шулай ук кирәк булган очракта – нәтиҗә комиссияләр, экспертлар һ. б.

17. Резерв фондыннан акчалар бары тик җирле дәрәҗәдә генә гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанслауга бирелә. Балык Бистәсе муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары (аларның оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан), җирле үзидарә органнары гадәттән тыш хәл килеп чыккан көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча Башкарма комитет җитәкчесенә резерв фондыннан акча бүлеп бирүне сорап мөрәҗәгать итә алалар. Мөрәҗәгатьтә матди зыян күләме, оешмаларның, җирле бюджетларның, иминият фондларының һәм башка чыганакларның гадәттән тыш хәлне бетерүгә бүлеп бирелгән һәм тотылган акчалары күләме, шулай ук аларның матди һәм финанс ресурслары резервлары булуы турындагы белешмәләр күрсәтелергә тиеш.

18. Резерв фонды акчаларының максатчан тотылуын тикшереп тору максатларында комиссия, Башкарма комитет җитәкчесе федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, барлык милек рәвешләрендәге оешмалардан, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм вазыйфаи затлардан, шулай ук турыдан-туры резерв фонды акчаларын алучылардан кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга һәм алырга мөмкин.

19. Резерв фонды акчаларын алучылар тапшырган белешмәләрнең яисә документларның дөрес булмавы факты ачыкланган очракта, акчалар Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының казначылык счетына ирекле рәвештә түләнә, ә түләүдән баш тарткан очракта - суд тәртибендә түләтелә.

Резерв фондыннан бүлеп бирелгән акчалар тулысынча файдаланылмаган очракта, файдаланылмаган акчаларның калдыклары кире кайтарылырга тиеш.

20. Ел йомгаклары буенча башкарма комитет Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына резерв фонды акчаларының тотылуы турында хәбәр итә.

21. Резерв фонды акчаларыннан максатчан файдалануны Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тикшереп тора.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 01.08.2024
№ 206пи карары белән
расланган

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | |
| Ногманова Ильсия Малик кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Комиссия рәисе урынбасары: | |
| Хәкимуллин А.А. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Комиссия сәркатибе: | |
| Бояринцева С.С. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Ризаев Д.Н. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Керженцева Г.Ф. | Балык Бистәсе муниципаль районының "Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ директоры (килешү буенча) |
| Әхмәтҗанова А.Р. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Исмәгыйлов Р.Д. | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Җамалиева Д.Х | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе» МКУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кәлиев Б.Р. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |